КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 август г.Казань № 1055

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2022 ел, 11 апрель, 342 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2022 ел, 11 апрель, 342 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка

татар текстында «җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге)» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы милкендәге алына торган җир кишәрлеген җир кишәрлегенә (җир кишәрлекләренә) алмаштыру юлы белән» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлегенең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) базар кыйммәтен бәяләгәннән соң, 30 көн эчендә җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип таныврга;

унынчы абзацта «имза куелган килешү» сүзләрен «имза куелган шартнамә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин